# A REVIEW OF ERCAN ALKAYA'S MONOGRAPH *THE MISHAR DIALECT OF THE TATAR LANGUAGE* (ERCAN ALKAYA. MIŞER TATAR TÜRKÇESİ. ISTANBUL: KESİT YAYINLARI, 2014. 671 P.)

**Ferits Yusufovich Yusupov,**
Kazan Federal university,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russia,
ferits@yandex.ru.

The review analyzes the monograph "Mişer tatar türkçesi" by the Associate Professor of Elazig University (Turkey) Yerzhan Alkaya, who is well-known in the scientific community of Tatarstan owing to his works on the Tatar language and Tatar dialectology, published in Istanbul, in the Kesit Yayınlar publishing house. The young talented Turkish scholar made a major contribution to Tatar dialectological research with this work. The book is based on the systemic and synchronous method which allows the author to highlight all levels of the Mishar dialect. The author of the monograph also reveals the complicated history of Tatar-Mishars who played an important role in the formation of the Tatar nation. In his opinion, Mishars lived in close contact with future Kazan Tatars as early as the time of the Bulgar states. As a result of age-old communications, the two ethnic groups developed common features in language and life, which brought these related groups closer together. According to the author of the monograph, the phenomena, specific to the Mishar dialect, contribute to the variety and richness of the language palette inherited from the Old Turkic language, which is the common basis for all modern Turkic dialects.

The appendix of the book contains examples of folk literature and ethno-linguistic materials, which give an idea of the Tatar-Mishars' rich spiritual culture. Scholars recognize Yerzhan Alkaya's monograph as a major contribution to the evolution of the Tatar language.

**Key words:** the Tatar language, the Mishar dialect, Tatar speeches, history of the Mishar-Tatars, the Old Turkic language, the Kipchaks.

The Tatar language has been the focus of scientific research since the emergence of Turkic Language Studies. In fact, their foundation was laid by the works of I.Giganov, I.Khalfin, A.Troyanskiy, A.Kazambek, and V.Radlov, dedicated to the study of the Tatar language. At that time the scholars were also exploring the Tatar language as the main object of Linguistic Studies, and often referred to it in their comparatively-historical research as a model expressing the essence of the Turkic languages. It was a means to discover linguistic phenomena which help to explain language patterns and changes in the Old Tatar and modern Turkic languages. At the same time, turcologists are primarily interested in dialects, which developed due to the influence of the speech of different Turkic tribes. Young researchers into grammar, who had thought that studying classic languages was the lot of the privileged, began to follow the example of A.Kazambek who propagated Ferdinand de Saussure's ideas in Russia. The idea that languages and dialects should be studied in close connection with the nations and tribes, who spoke them, became the young grammarian's codex. This idea was also accepted by the members of the Kazan Linguistic School as its main methodological basis.

Moreover, these ideas are reflected in the history of Tatar dialectological science and are shared by foreign scholars who work in the area of Tatar language. Yerzhan Alkaya, Head of the Department of Modern Turkish Dialects and Literatures at the Faculty of Humanities and Social Sciences of Firat University (Turkey) is one of these scholars. Yerzhan was born and lived in Elaziğ province. He graduated from Firat University, completed his postgraduate studies and defended his doctoral thesis under the supervision of the outstanding Turkish linguist Ahmet Buran. His teacher trained him to be an expert in Turkic languages. Consequently, his first works were devoted to modern Turkic languages, especially the Kipchak languages. Yerzhan Alkaya's monograph "Kuzey Grubu Türk Lehçelerınde" Edatlar, Manas Yay and Elazığ, 2007 (Auxiliary parts of speech in the North Turkic languages. Elazığ: Manas, 2007) is very popular with Turkic language experts. The scholar compiled many textbooks and methodological recommendations for students and a wide scientific audience. I discovered that Yerzhan Alkaya is a Tatar language expert after reading his book "Sibirya tatar türkçesi", published in one of the best publishing houses "Turkish Studies" (Ankara-Turkey, 2008). This monograph differs from all works that analyze the language features of Siberian Tatars in its fundamental character, versatility, and depth of knowledge.

Yerzhan Alkaya's book "The Mishar Dialect" (Istanbul, 2014. – 671 p.), which was published this year, is devoted to the study of the Mishar dialect of the Tatar language by means of the systemic and synchronous method. The title of the book first puzzles the readers, however, later they find out that it studies the Mishar dialect as one of the main dialects of the Tatar language. At the beginning of this article we mentioned the ideas of the Kazan Linguistic School with respect to the studies of Turkic dialects and speeches. We meant to emphasize the respect of the author of the monograph for the scientific heritage of the Russian scholars. Yerzhan Alkaya uses the same methods, and studies the language, its dialects, and speeches along with the history of the nations who speak them.

But who are the Mishars? Actually, the Mishars are the people who have left a great mark on human civilization. They are famous among the nations for their courage and bravery, they are diligent, high-toned and wise, and have a special view of life, which helps them out of complicated real-life situations, they love the place where they live, beautify it, and enjoy it, and they can set an example to follow for other nations. The scholar Yerzhan Alkaya expresses his warm attitude towards the Mishars in the chapters of his book devoted to the Mishar ethnonym, where he analyzes and discovers their long history. The author of the scientific monograph explains the phenomena, which to a certain extent are familiar to its readers, to those who know the Turkish language, and he does it in such a way that the readers remember them. In the first instance, the Mishars are one of the three big ethnic groups, which earned the respect of the Turkic nations and played an important role in creating the Tatar nation. In the second instance, the speech used by the Mishars is one of the most important dialects in the Tatar language formation. The scholars always note the role of the Mishar dialect in the Tatar literary language formation. Thus, the Mishar dialect contributed to the richness and flexibility of Tatar, and made it possible to explain different terms in a plain way. In the works of G.Kandauy, Sh.Kamal, M.Djalil, G.Kutuy, K.Nadjmi and Kh.Tufan each sentence is like gold. I think the Mishar youth, who did their best to create the Tatar national identity, deserve our congeners' respect.

But how did our brave and talented countrymen, descendants of ancient Kipchaks, get the name Mishars? The author explains it with the help of the legends, which throw light upon the origin of the name. For example, the word *mishar* meant military or soldierly in the Old Egyptian language. Mamluks came to Egypt to be warriors. Egyptian monarchs let them stay, as they were experienced and faithful soldiers. It should be emphasized, that the word *mishar* is derived from the word *madg* in Arabic, which means *war*. Note, that the word *magyar (mishar)* means a soldier. The author bases his explanations of the structure and meaning of the word *mishar* on M.Z.Zakiev's theory. As is known, this word consists of two parts *mish+ar*, the stem *mish//mesh//beshe* means *a tree, a conifer, a forest* in the Old Turkic language, and the part *er//ar* means *a man*, in other words, *a forest man*. The Russians called this Kipchak tribe the *heath people* or *Cumans*. According to Yerzhan Alkaya, the Mishars lived together with other nations from the North side of the Black Sea to Altay, consequently, the word *mishar* had different phonetic variants of pronunciation (miyer, mashchar, moyar, machar/magyar, bachachr, modor, madyr, mizhgar), and there can be different interpretations of the meanings of this word, but the scholars are sure about its structure. Y.Alkaya thinks the fact that the word *mod//modo*, which M.Z.Zakiev uses in his works, meaning *a tree* in the Mongolian languages, is one of the arguments which substantiates this theory. The scholar also cites the following meanings of the word: the Mishars lived in the famous Russian area of Meshchyora long ago and it is possible that the name of the place became an ethnonym of one of the Turkic tribes, who lived there. This word also meant a military man in the Old Egyptian and Arabic languages, and the Tatars who came back after the Kazan Khanate disintegration and became guards in the Eastern part of Russia. In this regard, the chapter devoted to the history of Mishars living in different Turkic states, will attract the attention both of Tatar readers and all those interested in the Tatar-Mishars. The author suggests his idea concerning the Mishars' origin: the Mishars originated from the assimilation of the Burtas, Finno-Ugric, and Magyar tribes of Old Kipchak nation. The Mishars all have reasons to be considered an independent Turkic ethnic group which has lived from ancient times to the present day. The author of the monograph is against of the idea of separating the Mishars from the Turkic land. He mentions being in opposition to the Russian historian V.V.Vilyaminov-Zernov and his contemporaries of the 19$^{th}$ century, as well as Finnish scholars, who thought that the Mishars were Tatarized Mordva, or that they came from the Meshchyora nation of Finnish origin living on the bank of the river Uka (Oka) long ago. Y.Alkaya believes there is no information to prove

that the Meshchyora nation ever existed and no data on its language in primary sources. If Ancient Mishars came from Finns and spoke their language, the Mishar dialects would preserve Finnish and Magyar (Hungarian) words. The scholar expands on this idea and cites G.Akhmerev, an expert on the history of the Mishars, who established that there are many Old Turkic words in their language. Y.Alkaya goes on to say that if Ancient Mishars were Magyars who had adopted the Turkish language from Bulgar Tatars, then there whould be Bulgar words in their language. These facts support his idea that the Mishars are of Turkic origin. To conclude, the scholar draws an inference that the Mishar Tatars, as well as the Kazan Tatars, belong to one of the groups originating from Bulgars, Kipchaks, and Khazars. The book contains data from primary sources, language and culture to substantiate this theory.

The dialectologist provides information about the history of the Mishars in the period of their residence in the Meshchyora place, on the bank of the rivers Moksha and Tsna, considered to be their motherland. He also describes the Mishars' longstanding relationships with the Kazan Tatars. These lands, called Meshchyora yurt, first belonged to the Russian Knyazh. From 1298 they were in the possession of the Golden Horde and later were given to the Moscow principality by Tokhtamysh khan. Ulugh Muhammad gave these lands back to the Tatars in the time of the Kazan Khanate development. The author of the monograph comes to the conclusion that these events brought Kazan and Mishar Tatars closer together.

The author notes the fact that the word *mishar* is both an ethnic term and a word meaning a social stratum. After conquering the Khanate of Kazan, the Russian monarchy made Mishars, who helped to defeat Kazan, guard the Eastern border line from the neighboring Kazakhs and Siberian Tatars. The word *mishar* was used for the ethnic group and with time it began to mean a social group of military men who guarded the Eastern border of the Russian state.

Yerzhan Alkaya suggests the idea that the Mishars played an important role in in the formation of the Tatar nation as well as Russian, Bashkir, Mordva, and other nations, who lived in the Volga-Ural region. The main idea of the book is the scholar's theory, that Mishars, who are similar to Tatars in their language, religion, traditions, and customs, originated (again, like the Tatars) from the Turkic tribes, and they are like two wings of one nation. The importance of such an idea increases with time, as attempts are made to divide the Tatar nation.

Although Mishars did not form their own nation, it is a fact that they made contributions to the creation of many Turkic nations. Yerzhan Alkaya thinks that the Kipchaks-Cumans, living in the Bulgar state, were the Mishars' ancestors, and then the Kipchaks imbibed the Bulgars of the Volga region. But a large part of the Mishars have saved their ethnic identity. According to the book, the Mishars of the Ryazan, Nizniy Novgorod, Tambov, Penza, Ulyanovsk and Saratov regions, and the Republic of Mordovia lived separately from other groups of Tatars, in this way preserving more of the distinctive features of their language, culture, and everyday life. On the contrary, the nations who lived in Tatarstan and Bashkortostan became very close to the Kazan Tatars. According to the scholar's observations, the characteristic features of the Mishar language faded away with the years, and most intensively in the late 20$^{th}$ and the early 21$^{st}$ centuries. The author notes, that nowadays, the peculiarities of the Mishar dialect, set against other Tatar accents, especially the Kazan Tatar (Middle) dialect, keep smoothing out.

Now, I will focus on Yerzhan Alkaya's designation of the place that the Mishar Tatar occupies among other Turkic languages. It is necessary to remind readers about the following information for reference. The classification of the Tatar dialects and accents is based on the ethnolinguistic approach, in other words, on the characteristic features of ethnic groups belonging to one nation. The dialectological system of the Tatar language consists of the Kazan Tatar (Middle), the Mishar Tatar (Western), and the Siberian Tatar (Eastern) dialects. In the past, this classification was believed to be incorrect, as it threatened the nation's unity, however, I was not able to find any other appropriate names for the Tatar dialects. Each ethnic group has a dialect with its own distinctive sociolinguistic features. Accents, with the same features, can be found within these three dialects. Yerzhan Alkaya also defined the language variants of the Tatar dialects system. He indicated that the Mishar dialect is divided into similar, independent accents, the difference is in the retention of 'ch' and 'ts', which means that the local varians of the Mishar dialect are close, they are stable, and this similarity, in its turn, is the evidence of the unity of our language, in spite of the fact that it functions in a large territory.

The main chapters of the book are devoted to the phonetics, morphology, and syntax of the Mishar dialect. Each of these chapters is a novelty of Tatar dialectology. I hope this monograph will be a model for further research on the Tatar dialects.

Dialectal phonetics is considered to be the most under-researched area of Tatar dialectology in Russia. Obviously, this area of scientific research was poorly developed at the beginning of the 20th century. It was V.V.Bogoroditskiy, G.Sharaf, U.Bajchura, and F.G.Iskhakov, who made major contributions to Tatar linguistics, and who founded the phonetics of the Turkic languages. The century-old phonetics research of those times succeeded in describing the phonetic systems of Tatar accents, solely identifying the difference between phonemes and the cases where one phoneme was replaced by another without specifying the causes and reasons for this sociolinguistic phenomenon. In my opinion, the discriminating method used in the dialectology of those times hindered effective research. Attempts were made to develop historical dialectology at the end of the 20th century, but the foundations of the science were not laid. Consequently, an understanding of the phonetic system of Tatar accents through the prism of the Old Turkic language could not be gained. The historical phonetics of modern languages, especially of the Turkic languages, was studied by V.V.Radlov on the basis of the Tatar language materials.

This aspect of the language is thoroughly analyzed in the book “The Mishar Dialect”. The chapter begins with the description of the sound system. Each vowel and consonant sound of the accent is defined, their places in the classification of sounds are identified and their articulatory and acoustic characteristics are carefully described. Each sound is compared with its variant in the Old Turkic language, and if there are changes specific to this accent, then their causes are given. It is the first time the Mishar dialect has been studied in this way. Phonetic laws are compared with blood pressure. This comparison aids an understanding of the way changes in the system of sounds occur. Dramatic changes in language begin with changes in pronunciation and their influence on the meaning of words. These phenomena can be holistic and local depending on the intensity of internal and external factors. The changes that caused the separation of the Tatar language from the Old and Modern Turkic languages occurred due to these factors. If the vowel system of the Kazan and Siberian Tatars (apart from the Baraba dialect) has shifted to a new scale, this shift is still in progress in the Mishar dialect. The rich material of numerous written sources presented in the book helps us to understand the stages of historical change. However, unlike the other Tatar dialects the Mishar dialect has saved more of its Old Turkic characteristics.

Phonemes are the indivisible elements of the language which can undergo certain changes in speech caused by different combinatorial variations. The number of such changes described in the book might come as a surprise for the reader. The book is of interest for that matter as well. We would like to conclude our review with citing the scholar’s ideas about phonetics. In spite of its rich phonetic system and numerous linguistic patterns, t he Mishar dialect has never been compared with the Tatar literary language and its numerous accents. The phenomena specific to the Mishar dialect can change and enrich the heritage of the Old Turkic language, which makes this our native dialect.

The chapter devoted to morphology has also become an important novelty of Tatar dialectology. Morphology can hardly be studied apart from lexical morphology. However, until today, no information has been found about the part of linguistics in the works of Tatar dialectologists, as if words have never been formed in our numerous accents. Yerzhan Alkaya proves that this element of the Mishar dialect is very productive. He focuses on the common elements of the Mishar dialect and the Tatar language, literary Tatar language and other dialects, showing the role the dialect plays in enriching our vocabulary. The author expresses his hope that some methods of word-formation and suffixes can be used to enrich Tatar vocabulary. In the chapter on morphology, the scholar proves that the Mishar dialect is a real successor of the Old Turkic language.

The chapter devoted to the parts of speech is distinguished by its comprehensive approach and detailed analysis. The scholar studies these linguistic phenomena in connection with grammatical categories, showing the richness of the nominal declension forms. The author, unlike Tatar dialectologists, suggests the possibility of the predicative category in the form of number, tense (present and past), and conditionality. Y.Alkaya’s theory enables the researcher to view this linguistic phenomenon from a different perspective.

The author’s idea should be of interest for Tatar linguists; that particles and conjunctions should be classified according to their functions and have the common name linking words as well as his theory of postpositions and their relations with nouns.

In its concluding part, the monograph contains ethnolinguistic material about oral folk arts and the everyday life of the Mishars. This chapter proves that Tatar Mishars are an ethnos, whose wealth is in their intellectual culture. Yerzhan Alkaya divides

this material into two parts in accordance with the difference in the retention of the 'ch' and 'ts' groups. It enables him to prove that Mishars are united in their intellectual culture. In the second part, the scholar has begun to study the Tatar-Mishars' folklore as an area of scientific research.

While reading the book, I imagined a middle-aged handsome man, sitting in front of a computer in his flat in Elazığ, which is situated between the blue mountains of Turkey, a man, who was thinking about Tatar-Mishars, living in the picturesque lands between the Volga and Ural rivers, who was willing to tell all the world about these people. Of course, I thought, Yerzhan Alkaya should be one of these young talented national scholars able to introduce our ethnic groups to the whole world.

---

# ЭРҖАН АЛКАЯНЫҢ «МИШӘР ДИАЛЕКТЫ» (ERCAN ALKAYA. MIŞER TATAR TÜRKÇESİ. ISTANBUL: KESİT YAYINLARI, 2014. 671S.) МОНОГРАФИЯСЕНӘ БӘЯЛӘМӘ

**Фәритс Йосыф улы Йосыпов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
ferits@yandex.ru.

Бәяләмәдә татар теле, аның диалектлары буенча басылган гыйльми хезмәтләре белән Татарстанның фәнни җәмәгатьчелегенә яхшы таныш булган Фрат университеты доценты Эрҗан Алкаяның 2014 елда Стамбулда нәшер ителгән «Мишәр диалекты» монографиясенә тирән анализ ясала. Бу хезмәте белән Төркиянең талантлы яшь галиме татар диалектологиясе фәненә зур өлеш кертә. Фәнни эзләнүләрдә системалы-синхрон методны куллану мишәр диалектының барлык өлкәләрен дә бер дәрәҗәдә тирән итеп яктыртырга мөмкинлек биргән. Авторның татар халкын формалаштыруда әһәмиятле урын тоткан татар-мишәрләрнең тарихы турындагы фикерләре дә игътибарга лаек. Галим фикеренчә, татар-мишәрләр казан татарлары белән Болгар дәүләтләре чорыннан ук тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Шуның нәтиҗәсендә телдә, тормыш-көнкүрештә бу ике төркемне бер-берләренә тагын да якынайта торган уртак рухи-мәдәни күренешләр барлыкка килгән. Хезмәт авторы мишәр диалектына хас булган күренешләрнең борынгы уртак төрки телебездән килгән мирасыбызны тагын да төрләндереп, тагын да баетып җибәрүен ассызыклый. Шуңа күрә бу диалект телебезнең яшәешендә бүгенгә кадәр уңай роль уйнап килә.

Китап татар-мишәрләрнең халык иҗаты, тормыш-көнкүреш мизгелләрен чагылдырган этнолингвистик материаллар җыелмасы белән тәмамлана. Бу бүлек татар-мишәрләрнең бай рухи мәдәнияткә ия булган этнос икәнен расларга ярдәм итә. Эрҗан Алкаяның бу хезмәтен галимнәр татар теле белемен үстерүгә керткән өлеше итеп кабул иттеләр.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, мишәр диалекты, татар сөйләшләре, борынгы төрки тел, кыпчаклар.

Тюркология фән буларак барлыкка килгән чорлардан ук татар теле игътибар үзәгендә була. Дөресен генә әйткәндә, аның нигезен И.Гиганов, И.Хальфин, А.Троянский А.Казем-бек, В.Радловларның татар телен өйрәнүгә багышланган хезмәтләре тәшкил итте. Ул елларда галимнәр, татар телен тел белеменең төп объекты буларак өйрәнүдән тыш, аны чагыштырма-тарихи эзләнүләрдә дә төрки телләрнең асылын чагылдыра торган эталон буларак кулланулары гадәти күренеш иде. Татар теленең борынгы һәм хәзерге төрки телләрдәге закончалыкларны һәм үзгәрешләрне аңлатырга ярдәм итә торган күренешләргә ия булуы моңа сәбәп була. Шул ук вакытта, тюркологларны, беренче чиратта, төрле мөстәкыйль төрки кавемнәр катнашында формалашкан шивәләр дә кызыксындыра. Моңа кадәр классик телләрне өйрәнүне генә дәрәҗә итеп санаган яшь грамматистлар Россиядә Фердинанд Де Сосюр идеяләрен таратучы А.Казембек тирәсендә тупланалар. Телләр һәм шивәләр шул телләрдә сөйләшә торган халыклар һәм кавемнәр белән аерылгысыз бәйләнештә каралырга тиеш дигән яшь грамматистлар кодексы саналган фикерне Казан лингвистик мәктәбе вәкилләре дә төп методологик нигез буларак кабул итәләр.

Бу карашлар татар диалектологиясе фәне тарихында да үзенең чагылышын тапты. Ул

гына да түгел, татар теле өлкәсендә эшләүче чит ил галимнәре дә әлеге фикер яклы. Фрат (Төркия) университетының Инсани фәннәр бүлегенең хәзерге төрки телләр һәм әдәбиятлар кафедрасы мөдире Эрҗан Алкая – шундый галимнәрнең берсе. Эрҗан Элазыг вилаятенда туып үскән, Фрат университетын, Төркиянең күренекле телчесе Әхмәт Буран җитәкчелегендә аспирантураны тәмамлап, докторлык диссертациясен яклаган. Остазы Әхмәт хуҗа аны төрки телләр буенча тирән белемле белгеч итеп әзерләгән. Шунлыктан аның беренче хезмәтләре хәзерге төрки телләр, аеруча кыпчак телләренә багышлана. Эрҗан Алкаяның «Kuzey Grubu Türk Lehçelerınde». Edatlar, Manas Yay., Elazığ, 2007 (Төньяк төрки телләрдә ярдәмче сүз төркемнәре. Элазыг: Манас, 2007) монографиясе төрки тел белгечләренең кул китабына әйләнде. Моннан тыш галимнең студентлар һәм киң катлам фәнни җәмәгатьчелек өчен язылган дәрес китаплары, күпсанлы методик кулланмалары бар. Эрҗан Алкая иң дәрәҗәле нәшриятларның берсе «Turkish Studies» (Анкара-Төркия, 2008) басмаханәсендә дөнья күргән «Sibirya tatar türkçesi» дигән хезмәте белән минем өчен татар теле белгече буларак ачылды. Галимнең бу монографиясе Себер татарларының тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр арасында үзенең фундаментальлеге, киңкырлыгы һәм фәнни тирәнлеге белән аерылып тора.

Эрҗан Алкаяның быел дөнья күргән «Мишәр диалекты» (Стамбул. 2014. 671б.) хезмәте татар теленең мишәр диалектын системалы-синхрон метод белән өйрәнүгә багышланган. Китапның исеме укучыларны беркадәр шөбһәгә салса да, хезмәт мишәр диалектын татар теленең төп диалектларының берсе итеп өйрәнүгә багышланган. Мәкаләбезнең башында Казан лингвистика мәктәбенең төрки сөйләшләр һәм шивәләрне өйрәнү өлкәсендәге карашларына тукталып китү, китап авторының Россия галимнәре кулланган әлеге игелекле методларны кабул итеп, аларның фәнни мирасларына зур хөрмәт белән каравын күрсәтү максатыннан чыгып эшләнгән иде. Эрҗан Алкая, Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре кебек үк, телне, сөйләшләрне, шивәләрне шул лөгатьтә сөйләшүче халыкларның тарихына бәйләп өйрәнә.

Кем соң ул мишәрләр? Дөрестән дә, кешелек цивилизациясендә тирән эз калдырган, дөнья халыклары арасында үзләренең батырлыклары, гайрәтлелекләре белән дан казанган, тырышлыклары, югары әхлаклары, зирәклекләре, тормыш чоңгылларыннан чыгарга ярдәм итә торган тирән тормыш фәлсәфәсенә ия булган, яши торган җырләрен, тормыш-көкүрешләрен матур итеп бизәп, аннан тәм таба белүләре белән әйләнә-тирә халыкларга үрнәк булып торган мишәрләр кемнәр соң алар? Китапның мишәр этнонимын, аларның ерак тарихларын ачып бирүгә багышланган өлешләрендә галим Эрҗан Алкая мишәрләргә үзенең җылы карашын ачык белдерә. Фәнни монографиянең авторы төрек телле укучыларга күпмедер дәрәҗәдә билгеле булган мәгълүматларны һәркемнең зиһенендә озак сакланырлык итеп аңлата белә. Беренче чиратта, мишәрләр – төрки халыклар арасында зур ихтирам казанган татар халкын-милләтен барлыкка китерүдә катнашкан өч зур этносның берсе. Икенчедән, мишәрләр сөйләшә торган шивә – гомумтатар телен оештыруда иң әһәмиятле диалектларның берсе. Галимнәр мишәр диалектының татар әдәби телен формалаштырудагы әһәмиятен һәрдаим ассызыклап күрсәтәләр. Димәк, телебезнең бай, кешелек фикриятендәге иң нечкә, шул ук вакытта иң катлаулы төшенчәләрне дә бернинди авырлыксыз туган телебездә аңлатып бирә алу югарылыгында булуы мишәр шивәсенең дә турыдан-туры катнашы нәтиҗәсендә ирешел-гән. Шулай булмыймы соң. Г.Кандалый, Ш.Камал, М.Җәлил, Г.Кутуй, К.Нәҗми, Х.Туфан әсәрләренең һәр җөмләсе алтын бәясенә торырлык бит. Татар халкының дәүләтчелеген коруда, аның эшчәнлегендә җаны-тәне белән катнашкан, шушы изге юлда үзләрен кызганмыйча, дан-шөһрәт казанган мишәр егетләре һәм кызлары милләттәшләребезнең дога-ихсанына лаеклар дип уйлыйм.

Борынгы кыпчаклар канын йөрткән шушы гайрәтле һәм талантлы кардәшләребез ни өчен мишәрләр дип аталганнар соң? Автор үзенең китабында моның серләрен ачып бирергә ярдәм итә торган риваятьләрне мөмкин кадәр тулы итеп китерергә омтылган. Мәсәлән, борынгы мисыр телендә мишәр сүзе хәрби, гаскәри мәгънәсен аңлаткан. Мәмлүкләр Мисыр дәүләтенә шул максат белән килгәннәр дә инде. Мисыр патшалары аларны оста һәм тугрылыклы сугышчы булганнары өчен кабул иткәннәр. Шуны да әйтеп китик: *мишәр* сүзе гарәп телендә *мадж* сүзеннән чыгып, сугыш төшенчәсен белдерә, *маджар (мишәр)* сүзенең исә *сугышчы* мәгънәсенә туры килүен дә истә тотарга кирәк. Автор, мишәр сүзенең структурасы һәм мәгънәләрен аңлатканда, М.З.Зәкиев

гипотезасына да таяна. Билгеле булганча, әлеге сүз, *миш+әр* өлешләреннән торып, *миш//меш//беше* тамырлары борынгы төрки телдә агач, ылыслы агач, урман, *ер//әр* кисәге исә кеше мәгънәләрен аңлаткан, ягъни урман кешесе. Ләкин, билгеле булганча, кыпчак кабиләләреннән булган бу кавемне руслар дала кешесе (половец) дип атаганнар. Эрҗан Алкаяның фикеренчә, мишәрләр Кара диңгезнең төньяк ярларыннан алып, Алтайга кадәр җәелгән туфракларда башка күп халыклар белән яшәгәнлектән, *мишәр* сүзе төрле фонетик вариантларда (мийер, мәшчәр, мойар, мачар/мажар, бәчәчр, модор, мадыр, мижгар кулланылып, ул белдергән мәгънәләрдә дә төрлелек килеп чыгуы мөмкин, ләкин сүзнең структурасы галимнәрдә шик-шөбһә уятмый. М.З.Зәкиев хезмәтләрендә китерелгән *мод//модо* сүзләренең монгол телләрендә агач мәгънәсен белдерүен Э.Алкая әлеге гипотезаны куәтли торган дәлилләрнең берсе дип таный. Мишәрләрнең ерак тарихта русларның атаклы Мещера җирләрендә яшәүләре һәм туфрак исеменең анда яшәгән төрки кавемнәрнең берсенә этноним булып китә алу ихтималы да, шулай ук борынгы мисыр, гарәп телләрендә бу сүзнең гаскәри кешене аңлаткан мәгънәсе Казан ханлыгы җимерелгәннән соң яңадан кире кайтып, Россиянең көнчыгыш чикләрен саклаучы хәрби (йомышлы) татарларны белдергән мәгънәләре дә галимнең игътибарыннан читтә калмаган. Бу уңайдан мишәрләрнең төрле төрки дәүләтләр составында яшәү тарихын яктырткан бүлек тә татар укучысының гына түгел, бәлки татар-мишәр проблемасы белән кызыксынучы һәммә кешенең дә игътибарын җәлеп итәр дип уйлыйм. Автор мишәрләрнең килеп чыгышы турындагы фикерен ачык итеп әйтә: мишәрләр борынгы кыпчак кабиләләренең бортас, фин-угор, мажар кавемнәрен ассимиляцияләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Мишәрләр – борын-борын заманнардан башлап, бүгенге көнгә кадәр яшәүче мөстәкыйль төрки этнос булып саналырга хаклы. Монография авторы мишәрләрне төрки җирлектән аерып карауга кискен рәвештә каршы чыга. Ул XIX гасыр урталарында шундый фикер белән чыккан рус тарихчысы В.В.Вильяминов-Зернов һәм аның чордашларының, хәзерге фин галимнәренең мишәрләрне татарлашкан мордвалар, ягъни бик борынгы заманнардан бирле Ука (Ока) елгасы бассейнында яшәгән фин тамырлы мещера халкының дәвамчылары дигән карашын кабул итә алмавын белдерә. Аның фикеренчә, тарихи чыганакларда да мещера кабиләсенең булуын, аның нинди телдә сөйләшүен раслый торган мәгълүмат юк. Борынгы мишәрләр фин тамырлы һәм телле халыклар булган очракта, мишәр сөйләшләрендә хәзерге вакытта фин һәм мажар (венгр) сүзләре күзәтелер иде. Галим бу фикерне тагын да куәтләп, мишәр тарихы буенча танылган белгеч Г.Әхмәревнең алар телендә, киресенчә, күп кенә борынгы төрки сүзләренең сакланып калуы турындагы мәгълүматларын китерә. Э.Алкая әлеге галимнең, әгәр дә борынгы мишәрләр мажар булып, соңыннан төрек телен болгар-татарлардан үзләштергән булсалар, аларның телләрендә болгар сүзләре сакланып калган булырга тиеш иде дигән фикеренә дә кушыла. Бу аның мишәрләр элек-электән үк төрки нәселдән булган дигән фикерен тагын бер тапкыр расларга ярдәм итә. Галим, әлеге фикерләргә йомгак ясап, түбәндәге нәтиҗәгә килә: мишәр татарлары, казан татарлары кебек үк, болгар, кыпчак, һәм хазар төркиләренең катнашында формалашкан этносларның бер төркеме. Китапта бу фикер тарихи чыганаклардан китерелгән фактлар, тел һәм рухи культура үрнәкләре белән дәлилләнеп бара.

Диалектолог галим мишәрләрнең борынгы ватаны саналган Мокша һәм Цна елгалары буйлап урнашкан Мещера җирләрендә кичергән тарихлары, казан татарлары белән булган иң борынгы бәйләнешлары турында да мәгълүмат биреп баруны урынлы санаган. Тарихта Мишәр йорты (Мещерский юрт) дип аталган бу җирләр заманында рус кенәзлекләренең туфраклары булып саналса, 1298 елдан башлап Алтын Урда кул астына күчә, бераздан Туктамыш хан тарафыннан Мәскәү кенәзлегенә бирелә, Казан ханлыгына нигез салынган вакытларда исә Олуг Мөхәммәд бу җирләрне кире татарларга кайтара. Китапта әлеге вакыйгалар казан һәм мишәр татарлары арасындагы бәйләнешларны тирәнәйтүгә китерә дигән нәтиҗә ясала.

Китапта *мишәр* сүзенең этник термин гына түгел, бәлки социаль катламны аңлату үзенчәлеге дә автор тарафыннан игътибарга алынган. Рус дәүләте, Казан ханлыгын яулаганнан соң, көнчыгыш чик буйларын күрше казахлар һәм себер татарларыннан саклау вазифасын Казанны алуда катнашкан мишәрләргә тапшыра. Этнос исемен атау өчен кулланылган мишәр сүзе тора-бара рус дәүләтенең көнчыгыш чикләрен саклаучы ярым гаскәри социаль төркемне аңлата башлый.

Эрҗан Алкая мишәрләрнең татар халкын формалаштыруда гына түгел, бәлки рус,

башкорт, мордва, шулай ук Идел-Урал буйларындагы башка халыкларның этногенезындагы роле турында да кызыклы фикерләре белән уртаклаша. Галимнең казан татарларына тел, дин, гореф-гадәтләре белән бик тә якын булган мишәрләрнең бер үк төрки тамырдан килгән бер халыкның ике канаты итеп каравы әлеге китапның нигез концепциясен тәшкил итә. Татар милләтенең бөтенлеген таркату омтылышлары көчәйгән вакытта әлеге карашның әһәмияте тагын да арта төшә.

Мишәрләр үз дәүләтләрен кормасалар да, күп кенә төрки дәүләтләрне төзүчеләр арасында мишәр этносы вәкилләре булуы тарихта шактый билгеле факт булып санала. Эрҗан Алкая мишәрләрнең борынгы бабаларының берсе булган кыпчак-куманнар Болгар дәүләтләре составында күпләп яшәгәннәр, тора-бара кыпчаклар Идел болгарларын тулысынча ассимиляцияләштергәннәр дигән фикерне алга сөрә. Шулай да мишәрләрнең шактый зур өлеше үзләренең этник мөстәкыйльлекләрен саклап калганнар. Китап авторының фикеренчә, Рязань, Түбән Новгород, Тамбов, Пенза, Ульяновск, Саратов өлкәләре һәм Мордовия Республикасындагы мишәрләр, күп гасырлар буенча татар халкының башка төркемнәреннән чагыштырмача ерак яшәгәнлектән, телдә, рухи мәдәнияттә, тормыш-көнкүреш өлкәләрендә борынгы үзенчәлекләрне күбрәк саклаганнар. Киресенчә, Татарстан, Башкортостан территорияләрендәге төркемнәр бу яктан казан татарларына бик якын торалар. Галимнең күзәтүләренә караганда, мишәр теленең үзенчәлекле билгеләре елдан-ел азая, XX гасырның азагы XXI гасыр башларында бу күренеш аеруча интенсив бара. Автор хәзерге вакытта мишәр диалектынының башка татар шивәләренә, аеруча казан татарлары (урта) диалектына каршы куела торган билгеләре, аларның кулланылыш активлыгы елдан-ел кими баруын билгеләп уза.

Эрҗан Алкаяның, мишәр татарларының тел үзенчәлекләреннән чыгып, аны татар һәм башка төрки телләр арасындагы урынын билгеләү принципларына да күз салып узыйк. Белешмә буларак, түбәндәге мәгълүматны укучыларның исләренә төшереп китү кирәктер дип уйлыйм. Татар теленең сөйләшләрен, диалектларын төркемләү этнолингвистик принципка, ягъни телнең җирле вариантлары шушы халыкны тәшкил итә торган этник төркемнәргә хас булган үзенчәлекләргә нигезләнеп башкарыла. Татар теленең диалект системасы казан татарлары (урта), мишәр татарлары (көнбатыш), себер татарлары (көнчыгыш) кебек диалектлардан барлыкка килә. Соңгы елларда диалектларны түбәндәгечә төркемләү халыкның бөтенлеген йомшартуга китерә дигән фикерләрне куертуга сәбәп булса да, мин аларны атау өчен башка терминнар таба алмадым. Диалектларның билгеле этносларның теленә бәйле рәвештә барлыкка килүе башка халыкларда да күзәтелә. Татар теленең шушы өч диалект тирәсендә уртак үзенчәлекләргә ия булган сөйләшләр туплана. Эрҗан Алкая да татар теленең диалектлар системасын тәшкил итә торган тел берәмлекләрен дөрес билгели. Ул мишәр диалектының нигездә бер төсле, мөстәкыйль сөйләшләргә бүленүе дә *ч*лаштыручы һәм *ц*лаштыручы төркемгә аерылудан гына гыйбарәт, дип билгели. Димәк, бу яктан да мишәр диалекты җирле вариантларның тотрыклы, бер-берләренә бик якын булулары, үз чиратында, мондый уртаклык, телебезнең зур территорияләргә таралып яшәвенә карамастан, бербөтен булуы турында сөйли.

Китапның төп бүлекләре мишәр диалектының фонетикасы, морфологиясе, синтаксис өлешләреннән тора. Бу бүлекләрнең һәркайсы татар диалектологиясенә зур яңалык алып килә. Мин бу монография киләчәктә татар диалектологиясе буенча язылачак хезмәтләргә өлге булыр дип өметләнәм. Россиядәге татар диалектологиясе фәненең иң йомшак җире итеп, диалекталь фонетиканы санарга була. Дөресен генә әйткәндә, бу фән XX гасыр башындагы дәрәҗәсеннән артык күтәрелә алмады. Уйлап карасаң, төрки телләрнең фонетика фәненә татар тел белемен үстерүгә зур өлеш керткән В.В.Богородицкий, Г.Шәрәф, Ү.Байчура, Ф.Г.Исхаков кебек галимнәребез нигез салганнар иде. Татар теле фонетикасы фәне уңышлы гына башланып китсә дә, бер гасырлык тарихы булган татар диалектологиясендә сөйләшләрнең фонетик системасын тасвирлау әдәби телдән аермалы булган яки әдәби телдә булмаган авазларны билгеләү, бер авазны икенче аваз белән алмаштырып килү күренешләрен теркәүгә генә кайтып калды. Бу күренешләрнең чыганаклары да, сәбәпләре дә күрсәтелмәде. Минемчә, диалектология фәненең беренче баскычларында бик популяр булган дифференциаль методның бүгенгә кадәр хөкем сөрүе моның төп сәбәбе булды. Татар диалектологиясендә XX гасырның азагында

тарихи диалектология фәнен башлап җибәрү омтылышлары булса да, аның фәнни нигезләре эшләнми калды. Шунлыктан татар шивәләренең фонетик системасын борынгы төрки тел күзлегеннән чыгып карау ныгып китә алмады. Хәзерге телләрнең, беренче чиратта, төрек тел белемендә шактый зур үсешкә ирешкән төрки телләрнең тарихи фонетикасы да В.В.Радлов хезмәтләре аша татар теле материаллары нигезендә башланып киткән иде ләбаса.

«Мишәр диалекты» хезмәтендә тел белеменең бу аспекты гаҗәеп тирән итеп яктыртылган. Бүлек авазлар системасын ачыклаудан башлана. Диалектның һәр сузык һәм тартык авазын барлау, аның авазлар классификациясендәге урынын билгеләү, артикуляцион һәм акустик үзенчәлекләрен ачыклау бик җентекле итеп башкарылган. Һәр аваз борынгы төрки телдәге варианты белән чагыштырыла, сөйләш өчен хас булган сыйфади үзгәрешләр күзәтелсә, аларның сәбәпләре ачыклана. Мишәр диалектының ике гасырлык өйрәнү тарихында мондый эзләнүләр, кызганычка каршы, беренче тапкыр гына башкарыла. Телдәге фонетик закончалыкларны кан тибешенә тиңлиләр. Алар телдә, бу очракта, авазлар өлкәсендә, үсеш-үзгәреш халәтен булдыруга шартлар тудыралар. Телдәге тирән үзгәрешләр, беренче чиратта, аның нигез ташлары булып саналган авазларның яңгыраш үзгәлекләреннән, аларның сүз мәгънәсенә тәэсир итү мөмкинлекләреннән башланып китәләр. Бу күренешләр, эчке һәм тышкы факторларның интенсивлыгына карап тулы һәм өлешчә булуы мөмкин. Шушы факторлар нигезендә татар телен борынгы һәм хәзерге төрки телләрдән аера торган үзгәрешләр барлыкка килгән. Казан һәм себер татарларының (бараба диалектын исәпкә алмаганда) сузыклар системасы бөтенләй икенче шкалага күчсә, мишәр диалектында бу күчеш әле дә дәвам итә. Китапта күп кенә язма чыганаклар һәм диалектлардан китерелгән бай тел материаллары безгә бу тарихи күчешнең этапларын аңларга ярдәм итә. Ләкин шулай да мишәр диалекты, татар теленең башка диалектларыннан аермалы буларак, үзенең борынгы төрки асылын күбрәк саклап кала алган.

Телнең бүленмәс берәмлекләре булган авазлары, сөйләм барышында бихисап үзгәрешләр кичерә башлап, бөтенләй башка сыйфатка күчәргә мөмкин. Моңа авазларның төрле комбинатор үзгәрешләре сәбәп була. Китапта китерелгән мондый үзгәрешләрнең күплегенә хәйран каласың. Бу яктан да китап үзенең җентекле анализы белән бик уңай тәэсир калдыра. Фонетика бүлегенә карата булган күзәтүебезне галимнең үз нәтиҗәсе белән тәмамлыйсы килә. Мишәр диалекты, фонетик системасының бай, тел законнарының тирәнлегенә карамастан, татар әдәби теле һәм күп санлы сөйләшләренә каршы куелмый. Мишәр диалекты өчен хас булган күренешләр борынгы уртак төрки телебездән килгән мирасыбызны тагын да төрләндереп, тагын да баетып кына җибәрәләр. Шуңа күрә дә бу диалект барыбыз өчен дә газиз булган халкыбызның терәк баганаларының берсе булып кабул ителә.

Монографиянең морфология бүлеге дә татар диалектологиясенә алып килгән мөһим яңалыклары белән аерылып тора. Морфологияне сүз ясалышы типларыннан башка күз алдына китерү бик авыр. Әмма татар диалектологларының хезмәтләрендә тел белеменең бу өлкәсенә соңгы көннәргә кадәр аз гына да игътибар бирелмәде. Әйтерсең лә безнең күп санлы сөйләшләребездә һәм диалектларыбызда сүзләр бөтенләй ясалмаган. Эрҗан Алкая телнең яшәү чыганагы булып саналырга тиешле бу өлкәнең мишәр диалектында гаҗәеп тә бай мөмкинлекләргә ия булганын ачып күрсәтә. Монда да ул мишәр диалектының гомум татар теле, әдәби телебез һәм башка диалектлары белән уртак якларына зур әһәмият бирә, мишәр диалектының сүз байлыгын арттырудагы ролен тулы итеп күрсәтүгә ирешә, мишәр диалектында кулланыла торган кайбер ысуллар һәм кушымчалар киләчәктә дә татар теленең сүз байлыгын арттыруда кулланылыр дигән өметен белдерә. Морфология бүлегендә дә галим мишәр диалектының борынгы төрки телнең тулы хокуклы мирасчысы икәнен дәлилләп бара.

Сүз төркемнәренә багышланган бүлек тә үзенең тулылыгы, җентекле аназизы белән аерылып тора. Галим аларны шушы сүз төркемнәренә хас булган грамматик категорияләргә бәйләп тикшерә, исемнәрдәге иялек, килеш, хәбәрлек формаларының байлыгын күрсәтүгә ирешә. Автор хәбәрлек категориясенең, татар диалектологларыннан аермалы буларак, берлек-күплек, заман (хәзерге, күреп беленгән үткән заман, ишетеп беленгән үткән заман һ.б.), шарт формаларында килә алу мөмкинлекләре турында сөйли. Э.Алкаяның бу алымы да безгә

сөйләшләребездәге тел күренешләрен башкача карау юлларын ачып күрсәтә.

Авторның кисәкчә, теркәгеч сүзләренең уртак вазифаларына карап төркемләнүе, аларның гомум «бәйләгечләр» исеме белән аталып йөртелүләре, бәйлекләр һәм аларның төрле килештәге исемнәр белән булган мөнәсәбәтләрен аңлатудагы карашлары да бездә, татар тел белеме өлкәсендә эшләүче галимнәрдә, зур кызыксыну уятты.

Монографик хезмәт мишәр-татарларның халык иҗаты, тормыш-көнкүреш мизгелләрен чагылдырган этнолингвистик материаллар җыелмасы белән тәмамлана. Бу бүлек татар-мишәрләрнең бай рухи мәдәнияткә ия булган этнос икәнен расларга ярдәм итә. Эрҗан Алкая бу материалларны, *ч*лаштыручы һәм *ц*лаштыру мишәр төркемнәренең иҗаты итеп, ике төркемгә бүлеп карый. Моның белән дә ул татар-мишәрләрнең телдә генә түгел, бәлки рухи мәдәниятләре буенча да бүленмәс бер этнос икәнен раслауга ирешә. Икенче яктан, галим бу гамәле белән фәндә татар-мишәр фольклорын фәнни өйрәнүне башлап җибәрә.

Китап белән танышып чыккан соң, Төркиянең берничә гарәп илләре белән чиктәш, зәңгәр таулар эчендә урнашкан Элазыг шәһәрендәге фатирларның берсендә компьютер артында, Идел белән Урал арасындагы гаҗәеп матур җирләрдә яшәүче татар-мишәрләр турында хыялланып, аларның гүзәллеген бөтен дөньяга сөйләр өчен асыл сүзләр сайлап утырган, үзе дә безнең мишәр егетләреннән һич кенә дә ким булмаган урта яшьләрдәге, сөйкемле бер ирне күз алдыма китердем. Әлбәттә, мин халкыбызның төрле төркемнәрен дөньяга матур итеп танытучы талантлы яшь галимнәреннән берсе – Эрҗан Алкая шундый булырга тиеш дип уйладым.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА МОНОГРАФИЮ ЭРЖАНА АЛКАИ «МИШАРСКИЙ ДИАЛЕКТ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА» (ERCAN ALKAYA. MIŞER TATAR TÜRKÇESİ. ISTANBUL: KESİT YAYINLARI, 2014. 671 S.)

**Феритс Юсупович Юсупов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, д.18,
ferits@yandex.ru.

В рецензии глубокому научному анализу подвергается монография хорошо известного научной общественности Татарстана своими трудами по татарскому языку и татарской диалектологии доцента Элазигского университета (Турция) Эржана Алкаи «Mişer tatar türkçesi», изданная в г. Стамбуле в издательстве Kesit Yayınları. Этим трудом молодой талантливый ученый Турции внес весомый вклад в татарскую диалектологическую науку. Книга написана с применением системно-синхронного метода, который позволил автору глубоко осветить все уровни мишарского диалекта. В ней также раскрывается сложная история татар-мишарей, игравших важную роль в становлении татарской нации. По его мнению, уже во времена булгарских государств мишари жили в тесном контакте с будущими казанскими татарами. В результате многовековых связей между двумя этносами в языке и быту образовались общие особенности, еще больше сблизившие эти родственные группы. По мнению автора монографии, явления, характерные для мишарского диалекта, содействуют многообразию и обогащению языковой палитры, унаследованной от древнетюркского языка, который является общей основой для всех современных тюркских языков и диалектов.

В книге в виде приложения представлены образцы народной литературы, этнолингвистические материалы, которые дают возможность иметь определенное представление о богатой духовной культуре татар-мишарей.

**Ключевые слова:** татарский язык, мишарский диалект, татарские говоры, история мишар-татар, древнетюркский язык, кипчаки.